ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

«19» 09 2025 ел Яр Чаллы № 3117

«Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проекты кысаларында «2020-2027 елларга Тукай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру максатында 2025 елның III кварталына Тукай муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метры бәясе нормативын раслау турында

«Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проекты кысаларында «2020-2027 елларга Тукай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру максатында, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берләшмәсе» коммерциясез партнерлыгының 2025 елның 27 август 265 номерлы хаты нигезендә һәм Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2025 елның 2 июль 394/пр номерлы боерыгын исәпкә алып,

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проекты кысаларында «2020-2027 елларга Тукай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарның торак шартларын яхшырту буенча чаралар үткәрүгә социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен, 2025 елның III кварталына Тукай муниципаль районы территориясендә гомуми торак мәйданының 1 кв. м бәясен 70114 сум 00 тиен күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев